**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
28 ноября 2016 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 25 декабря 1992 года № 1722-XII «О недрах» (в редакции Закона Республики Татарстан от 6 декабря 1999 года № 2486) (Ведомости Верховного Совета Татарстана, 1992, № 11 – 12; Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I часть); 2005, № 4 (I часть); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I часть), № 12 (II часть); 2014, № 1 – 2, № 4, № 5, № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 3) следующие изменения:

1) в части первой статьи 19:
а) абзац второй изложить в следующей редакции:
«соблюдение законодательства, норм и правил в области использования и охраны недр;»;
б) абзац восьмой изложить в следующей редакции:
«соблюдение требований по рациональному использованию и охране недр, безопасному ведению работ, связанных с пользованием недрами, охране окружающей среды;»;

2) в статье 89:
а) абзац одиннадцатый части первой изложить в следующей редакции:
«безопасное ведение горных и взрывных работ.»;
б) часть вторую признать утратившей силу;

3) в части первой статьи 93 слова «и утвержденных в установленном законодательством Российской Федерации порядке стандартов (норм, правил) в области геологического изучения, рационального использования и охраны недр» заменить словами «, норм и правил в области использования и охраны недр»;

4) в статье 95:

а) абзац третий изложить в следующей редакции:

«разработку норм и правил в области использования и охраны недр;»;

б) абзац пятый изложить в следующей редакции:

«осуществление государственного надзора за геологическим изучением, рациональным использованием и охраной недр;»;

5) часть первую статьи 97 изложить в следующей редакции:

«Задачами государственного надзора за безопасным ведением работ, связанных с пользованием недрами (далее – государственный горный надзор), являются предупреждение, выявление и пресечение нарушений пользователями недр или лицами, осуществляющими работы на участках недр, предоставленных в пользование пользователям недр, требований по безопасному ведению работ, связанных с пользованием недрами.»;

6) в части второй статьи 98 слова «должны выполнять требования утвержденных в установленном порядке стандартов (норм, правил)» заменить словами «обязаны обеспечить соблюдение требований».

**Статья 2**

В части пятой статьи 13 Закона Республики Татарстан от 28 марта 1996 года № 482 «О племенном деле в животноводстве Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 1996, № 4; 2002, № 12 (II часть); 2003, № 6; 2005, № 12 (I часть); 2007, № 4; 2009, № 1; 2011, № 6 (I часть); 2012, № 7 (I часть) слова «предусмотренный стандартом породы уровень продуктивности животных» заменить словами «установленный уровень продуктивности племенных животных».

**Статья 3**

Внести в Закон Республики Татарстан от 24 января 2001 года № 595 «О плодородии земель сельскохозяйственного назначения» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2001, № 1 – 2; 2005, № 1 (I часть); 2006, № 7 (I часть); 2010, № 5 (I часть); 2013, № 2 (I часть) следующие изменения:

1) абзац третий статьи 1 изложить в следующей редакции:

«государственное нормирование плодородия земель сельскохозяйственного назначения – разработка и утверждение норм и правил в области обеспечения плодородия земель сельскохозяйственного назначения;»;

2) абзац третий статьи 4 изложить в следующей редакции:

«соблюдать нормы и правила в области обеспечения плодородия земель сельскохозяйственного назначения;»;

3) статью 7 дополнить абзацем следующего содержания:

«государственное нормирование плодородия земель сельскохозяйственного назначения.».

**Статья 4**

Внести в Экологический кодекс Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 1; 2010, № 5 (I часть); 2011, № 6 (I часть), № 10 (I часть); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 40 (I часть) следующие изменения:

1) в части 1 статьи 2:

а) абзац двадцать седьмой после слова «документов,» дополнить словами «федеральных норм и правил,»;

б) абзац шестьдесят шестой после слов «нормативами в области охраны окружающей среды» дополнить словами «, федеральными нормами и правилами в области охраны окружающей среды»;

в) абзац шестьдесят седьмой после слова «документов» дополнить словами «, федеральных норм и правил,»;

2) в статье 15:

а) часть 2 после слов «а также» дополнить словами «федеральных норм и правил и»;

б) в части 3 слова «Экологические нормативы и нормативные документы в экологической сфере» заменить словами «Нормативы, федеральные нормы и правила и нормативные документы в области охраны окружающей среды»;

3) в статье 28:

а) наименование после слова «документы» дополнить словами «, федеральные нормы и правила»;

б) абзац первый части 1 после слова «документами» дополнить словами «, федеральными нормами и правилами»;

в) часть 2 после слова «документы» дополнить словами «, федеральные нормы и правила»;

г) часть 3 после слова «документы» дополнить словами «, федеральные нормы и правила»;

4) абзац второй части 2 статьи 67 изложить в следующей редакции:

«совершенствования законодательства в области охраны окружающей среды, создания нормативов и иных нормативных документов, федеральных норм и правил в области охраны окружающей среды;»;

5) абзац восьмой статьи 141 изложить в следующей редакции:

«безопасное ведение горных и взрывных работ.».

**Статья 5**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
12 декабря 2016 года
№ 95-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 28 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Җир асты байлыклары турында” 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 4, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 19 статьяның беренче өлешендә:
а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә законнар, нормалар һәм кагыйдәләр үтәлүне;”;
б) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклауга, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне имин алып баруга, әйләнә-тирә мохитне саклауга карата куелган таләпләр үтәлүне;”;

2) 89 статьяда:
а) беренче өлешнең унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“тау эшләрен һәм шартлату эшләрен хәвефсез алып бару.”;
б) икенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

3) 93 статьяның беренче өлешендә “һәм җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, алардан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә Россия

Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган стандартлар (нормалар, кагыйдәләр)” сүзләрен “, җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә нормалар һәм кагыйдәләр” сүзләренә алмаштырырга;

4) 95 статьяда:

а) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә нормалар һәм кагыйдәләр әзерләү;”;

б) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“җир асты байлыкларының геологик өйрәнелешенә, аларның нәтиҗәле файдаланылуына һәм аларның сакланышына дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру;”;

5) 97 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрнең имин алып барылуына дәүләт күзәтчелеге (алга таба – тау эшләре дәүләт күзәтчелеге) бурычлары җир асты байлыкларыннан файдаланучылар яисә җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга файдалану өчен бирелгән җир асты байлыклары кишәрлекләрендә эшләр башкаручы затлар тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне имин алып бару таләпләрен бозуны кисәтүдән, ачыклаудан һәм булдырмаудан гыйбарәт.”;

6) 98 статьяның икенче өлешендә “хәвефсез алып бару буенча билгеләнгән тәртиптә расланган стандартларның (нормаларның, кагыйдәләрнең) таләпләрен үтәргә тиеш” сүзләрен “хәвефсез алып бару таләпләренең үтәлүен тәэмин итәргә тиеш” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

“Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында” 1996 елның 28 мартындагы 482 номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы бишенче өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 4; 2002, № 12 (II өлеш); 2003, № 6; 2005, № 12 (I өлеш); 2007, № 4; 2009, № 1; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш) “терлекләрнең продуктлылыгы токым стандартында каралган дәрәҗәгә” сүзләрен “нәсел терлекләре продуктлылыгының билгеләнгән күрсәткечләренә” сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

“Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында” 2001 елның 24 гыйнварындагы 595 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 1 – 2; 2005, № 1 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын дәүләт тарафыннан нормалаштыру – авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә нормалар һәм кагыйдәләр әзерләү һәм раслау;”;

2) 4 статьяның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендәге нормаларны һәм кагыйдәләрне үтәргә;”;

3) 7 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын дәүләт тарафыннан нормалаштыру.”.

**4 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 40 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендә:

а) егерме җиденче абзацта “документларның,” сүзеннән соң “федераль нормаларның һәм кагыйдәләрнең” сүзләрен өстәргә;

б) алтмыш алтынчы абзацта “нормативлар,” сүзеннән соң “әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге федераль нормалар һәм кагыйдәләр,” сүзләрен өстәргә;

в) алтмыш җиденче абзацта “документларның,” сүзеннән соң “федераль нормаларның һәм кагыйдәләрнең,” сүзләрен өстәргә;

2) 15 статьяда:

а) 2 өлештә “шулай ук әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә” сүзләреннән соң “федераль нормаларны һәм кагыйдәләрне,” сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлештә “Экология өлкәсендә экологик нормативлар һәм норматив документлар” сүзләрен “Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә нормативлар, федераль нормалар һәм кагыйдәләр, норматив документлар” сүзләренә алмаштырырга;

3) 28 статьяда:

а) исемендә “документлар” сүзеннән соң “, федераль нормалар һәм кагыйдәләр” сүзләрен өстәргә;

б) 1 өлешнең беренче абзацында “документлар белән” сүзләрен “документларда, федераль нормаларда һәм кагыйдәләрдә” сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 өлештә “документлар” сүзеннән соң “, федераль нормалар һәм кагыйдәләр” сүзләрен өстәргә;

г) 3 өлештә “документлар” сүзеннән соң “, федераль нормалар һәм кагыйдәләр” сүзләрен өстәргә;

4) 67 статьяның 2 өлешендәге икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә законнарны камилләштерү, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә нормативлар һәм башка норматив документлар, федераль нормалар һәм кагыйдәләр булдыру;”;

5) 141 статьяның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“тау һәм шартлату эшләрен хәвефсез алып бару.”.

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 12 декабре
№ 95-ТРЗ